КЫШКЫ ӘКИЯТ

Мамадыш районында яшәүче Роберт Сәлахетдинов кар һәм боздан могҗизалар тудыра

> 3

РӘШӘМЕ, ЧЫНБАРЛЫКМЫ?

Камал театры бу елның соңгы премьерасын тәкъдим итте

> 3

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

> 4

НОМЕРДА – ДОКУМЕНТ

Киләсе елларга Татарстан бюджеты ничек фаразлана?

> 5–42

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 193 (28966) | Чәршәмбе | 28 декабрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ЯҢА ЕЛНЫ КӨТКӘНДӘ

20 мең сум! Яңа ел бәйрәмнәрендә тиешсез урында салют-фейерверк аттыручыларга әнә шулкадәр штраф яный. Бәйрәм кәефе дип, чама хисе турында да онытмаска киңәш иттеләр. Яңа ел төнендә урамнарны 2 меңнән артык полиция хезмәткәре саклаячак. Татарстан Министрлар Кабинетында Яңа ел бәйрәмнәрендә куркынычсызлык чараларын тәэмин итү турында сөйләделәр.

Билгеле булганча, 19 декабрьдән Татарстанда янгынга каршы махсус режим кертелде. «Ул 8 гыйнварга кадәр гамәлдә булачак», – дип искәртте Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча җитәкчесе Рафис Хәбибуллин. Озын сүзнең кыскасы, салют, петардаларны теләсә кайда аттырырга ярамый. Бәйрәм кәефе шактый кыйммәткә төшмәгәе югыйсә.

– Яңа елда пиротехник эшләнмәләр шартлатырга теләүчеләргә 1 мең 150 махсус мәйдан оештырылды. Салют-фейерверкларны торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы, халык күп йөри торган урыннар һәм автомобиль юлларыннан – 30 метр, сәнәгать предприятиеләре, ягулык-энергетика комплексыннан 50 метр ераклыкта гына һавага җибәрергә рөхсәт ителә. Әлеге кагыйдәләрне үтәргә теләмәүчеләргә исә штраф яный. Физик затларга – 20 мең, урындагы затларга – 60 мең, юридик затларга исә 800 мең сумга кадәр штраф каралган, – дип кисәтте министр.

Беркемнең дә бәйрәм кәефен бозасы килми, билгеле. Шуңа күрә халык арасында да, пиротехник эшләнмәләр сата торган кибетләрдә дә профилактика чараларына бәйле эшне көчәйткәннәр. «400гә якын рейдка чыктык. Бәла китерергә мөмкин булган 141 очракны булдырмыйча калдык», – дип сөйләде Рафис Хәбибуллин. Сүзен куәтләп:

– Бу – күктән алган саннар түгел. Әнә пиротехник эшләнмәне рөхсәт ителмәгән урында җибәргән бер кешене социаль челтәрләр аша эзләп таптык. Интернетка видеоязма куйган. Нәтиҗәдә ул административ җаваплылыкка тартылды. Уеннан уймак чыгара язган кешегә 30 мең сум штраф түләргә туры киләчәк. Хәзер бөтен нәрсә ачык бит. Сак булыгыз! – дип тә әйтте ул.

Халык күпләп ял иткән урыннарда һәм юлда да уяулыкны югалтырга ярамый. «Без Яңа ел бәйрәмнәренең иминлеген тәэмин итү өчен әзерлек эшен ноябрьдә үк башладык. Хезмәткәрләр составын ачыкладык. Яңа ел төнендә урамнарга 2 мең 500 полиция хезмәткәре чыгачак», – диде Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының җәмәгать тәртибен саклау полициясе җитәкчесе урынбасары Фәргать Мөхәммәтҗанов. Кышкы каникул көннәрендә урамдагы иминлекне 400ләп «погонлы» саклар дип көтелә.

– Татарстанда барлыгы 150 чыршы шәһәрчеге эшләячәк. Бүген шуларның 40тан артыгында бәйрәм чаралары башланды инде. Барыннан да бигрәк, әнә шундый халык күпләп ял итә торган урыннар игътибар үзәгендә булачак. Былтыр Яңа ел төнендә чыршы шәһәрчекләренә, скверларга һәм паркларга 200 мең чамасы кеше чыкты. Быел да сәгать телләре унике сукканны чыршы тирәсендә каршы алырга теләүчеләр моннан кимрәк булмас, дип уйлыйбыз, – диде урынбасар.

Ни дисәң дә, бәйрәм – бәйрәм бит инде ул, сәрхушләр дә булмый калмас. Урамдагы исерекләрне барысын да якаларыннан тотып алып китәчәкләрме, дип тә кызыксынды журналистлар полиция вәкиленнән. «Аякта басып тора алганнарга, озатучысы булганнарга тимибез», – диде Фәргать Мөхәммәтҗанов. Эчеп, дөньясын онытып җибәргәннәрне исә айныткычка озатачаклар.

Полиция хезмәткәрләренә ярдәмгә Росгвардия вәкилләре дә чыгачак. «Иминлекне тәэмин итү өчен мөмкинлекләр җитәрлек», – диде Россия илкүләм гвардиясенең Татарстандагы идарәсе җитәкчесе урынбасары Марат Сәлахиев.

– Ничек кенә булмасын, чат саен полиция вәкилен куеп булмый. Бүгенге вазгыятькә бәйле рәвештә бурычларыбыз да арта. Бәйрәм арасында тәртип бозу очракларының күбесе исерткеч эчемлек кулланучыларга туры килә. Кемдер чамасын белә, ә кемгәдер диңгез дә тубыктан, – диде Фәргать Мөхәммәтҗанов.

Шешәне үз итүчеләр дигәннән, алар – ут-күз чыгуга да сәбәпче. Ел башыннан бирле республикада 4 мең 890 янгын очрагы теркәлгән. Быел 121 кеше янгында үлгән. «Ни кызганыч, Яңа ел бәйрәмнәрендә «кызыл әтәч»кә бәйле гадәттән тыш хәл очраклары ике тапкыр арта», – дип кисәтте Рафис Хәбибуллин. Сүзен саннар белән дә дәлилләп күрсәтте ул. Былтыр гыйнварның беренче ун көнендә республикада 101 янгын очрагы теркәлгән. Утта 8 кеше һәлак булган.

– Бәла-каза очракларының сәбәпләренә килгәндә, ут белән саксыз эш итү фаҗигагә китерергә мөмкин. Былтыр, мәсәлән, барлык янгын очракларының 38 проценты шуның аркасында килеп чыккан, – диде ул. – Хәмерне чамадан тыш артык куллану да яхшыга китерми. Узган ел Татарстанда бәйрәм ялларында исерекләр аркасында 17 янгын очрагы теркәлгән, 8 кеше һәлак булган. Бәйрәмнәр сөенечле хәлләр белән генә истә калсын иде!

Эльвира ВӘЛИЕВА

Әле соң түгел

Дуңгыз гриппы Россиянең барлык төбәкләрендә дә теркәлгән инде. Хәзерге вакытта ул – гриппның иң киң таралган штаммы. Шул ук вакытта соңгы атнада грипп һәм ОРВИ очраклары 7 процентка кимеп, чирләүчеләрнең гомуми саны 1,7 миллион кеше тәшкил иткән. Шуңа да карамастан, Роспотребнадзор башлыгы Анна Попова Яңа ел бәйрәмнәрендә дә, шуннан соң да санитария-эпидемиология чараларын үтәүне дәвам иттерергә кушкан.

Белгеч сүзләренә караганда, Яңа ел алдыннан чирләп китмәс өчен халык күп йөри торган җирләрне – кибетләр, башка җәмәгать урыннарын читләтебрәк үтү хәерле. Ә инде барырга кирәк булган очракта битлек кияргә, антисептиклардан файдаланырга, социаль дистанция сакларга кирәк. Ә иң мөһиме – вакцинация. Эпидемиологлар ышандырып әйткәнчә, прививка ясатырга соң түгел әле. Бүгенге барлык вакциналарда дуңгыз гриппына каршы компонентлар бар.

Ике тапкыр зуррак

Казанның «Кырлай» аттракционнар паркына алмашка Яңа Савин районындагы Җиңү паркы янәшәсендә балалар паркы төзелә. Башкала мэры Илсур Метшин әнә шулай дип белдергән. Исегезгә төшерәбез: Казансу яр буендагы «Кырлай» паркын быел язын сүттеләр. Май аенда анда булачак Җәмигъ мәчетенә нигез ташы салынды. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов эшләренең якын киләчәктә башланып китәчәген белдерде. Яңа парк өчен Җиңү паркы янәшәсендә 13 гектар мәйданлы җир кишәрлеге билгеләнгән. Элекке «Кырлай» паркы мәйданыннан ике тапкыр диярлек зуррак бу.

Кыйммәтле көннәр

1–8 гыйнвар – бәйрәм көннәре. Озын ялларда эшкә чыгучылар хезмәт хакын ике тапкыр күбрәк алырга тиеш. Хезмәт һәм мәшгульлек федераль хезмәте телеграм-каналында хәбәр ителгәнчә, Хезмәт кодексында бәйрәм көннәрендә эшләүчеләрнең хезмәтенә арттырылган күләмдә түләү гарантияләнгән. Яисә бәйрәмдә эшләүчеләргә башка вакытта ял бирелергә мөмкин. Бу очракта хезмәт хакы гадәттәгечә түләнелә. Ведомствода искәртеп үтелгәнчә, хезмәткә хокуклар санга сугылмаганда, «Онлайнинспекция.рф» порталында дәүләт хезмәт инспекциясенә мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Электромобильгә – «ягулык»

Татарстанда электромобильләр өчен 95 электр зарядкасы станциясеннән торган челтәр эшли башлаган. Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы матбугат хезмәте хәбәренә караганда, федераль программа кысасында Татарстан пилот проектны беренчеләрдән булып гамәлгә ашырган. Зарядка станцияләре республиканың 9 шәһәре һәм 10 районында булдырылган.

Бу эшкә 500 миллион сум тотылган. Шул исәптән 175 миллион сумы – федераль үзәктән. Станцияләрне булдыруга тотылган чыгымнар 6,5 елдан соң үзен аклаячак. Татарстанда барлыгы 171 зарядка станциясе әзер. Республика шәһәрләрендә аларга ихтыяҗ тулысынча канәгатьләндерелгән. Юлларны гына җиһазлап бетерәсе бар.

Яңгырлы бәйрәм

Татарстанда Яңа ел төнендә +1 градус җылы һәм яңгыр көтелә. Гидрометеоүзәк һава температурасының −4…+1 градус тирәсендә тирбәләсен фаразлый.

31 декабрьдән 1 гыйнварга каршы төндә республикада кар, шул исәптән юеш кар, урыны белән яңгыр явачак. Россия Гидрометеоүзәге фәнни җитәкчесе Роман Вильфанд сөйләп үткәнчә, бәйрәм төнендә ил территориясенең 80 проценты өлешендә һава температурасы нормага якын яки аннан югарырак булачак.

Исегезгә төшерәбез: узган ел Татарстанда Курантлар сукканда һава температурасы −6…−11 градус чамасы иде. Көндез 1 гыйнварда −2…−7 градус булды.

Дәүләт Советында

Аңлашу һәм берләшү елы

ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНЫҢ БЫЕЛГЫ ЭШЕНӘ НӘТИҖӘ ЯСАДЫ

Акча җитәрме, ниятләр тормышка ашармы? Татарстан Дәүләт Советына җыелган журналистлар аның җитәкчесеннән шул хакта борчылып сорашты. Фәрит Мөхәммәтшин исә барысы да яхшы буласына өметләндерергә тырышты. Нинди чорда да кешене өмет алып кала бит.

2022 ел турында

Сәясәт дисеңме, икътисадмы – катлаулы ел һәр тармакта үз эзен калдырды. Шулай да бу елны намуслы үтелгән юл, үтәлгән бурыч хисе белән озатабыз. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әйтмешли, шикләнүләргә, икеләнүләргә урын калдырмыйча, елны нәтиҗәле йомгаклыйбыз.

– Бернигә дә карамастан, республика куйган бурычларны һәм планнарны үти алды. Икътисад, сәнәгать, төзелеш, мобилизация, милләтара дуслык, социаль яклау җәһәтеннән, дисеңме… Махсус хәрби операциягә бәйле хәлләр, санкцияләр безнең көчле икътисадыбызга йогынты ясады, – диде Дәүләт Советы Рәисе. – Бу ел имтиханын республика да, халык та лаеклы рәвештә уза алды.

Фәрит Мөхәммәтшин республика халкына да рәхмәтле булуын әйтте. Алдарак әйтеп үткән бурычларны да Татарстанда яшәүчеләрнең эш сөючән һәм бернәрсәгә дә битараф булмавы бәрабәренә ирешелгән бит.

Аз эшләнмәгән, билгеле. Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, бюджет үтәлеп торган, халыкның тормыш сыйфатын яхшырту юнәлешендә дә эш алып барылган, гозерләрне тыңлаганнар.

– Без мобилизацияләнүчеләрнең гаиләләренә булышабыз, хәрби хәрәкәтләр зонасындагыларга ярдәм итү җаен табабыз. Бик күп гуманитар йөк тапшырдык. Депутатлар арасында да хәрби хәрәкәтләр зонасына китүчеләр бар, – диде Дәүләт Советы җитәкчесе.

Елга йомгак ясаганда, киләчәкне дә уйлыйсың, билгеле. Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, 2023 ел да икътисадый, социаль һәм сәяси яктан әллә ни җиңел булмас. Бу шартларда бердәмлекне саклап калу аеруча мөһим.

Бюджет акчасын санаганда

Очрашуда журналистлар киләсе елга кабул ителгән бюджет һәм дефицитның шактый булуын телгә алды. Барысына да акча җитәрме?

Ахыры 2 нче биттә >

САН

Дәүләт Советы 11 утырыш үткәргән. 234 сорау каралган, шуларның 200дән артыгы (ягъни 85 проценты) социаль юнәлешкә бәйле.
Башка парламентлар белән хезмәттәшлек турында әйткәндә, Татарстан Россиянең 37 субъектында хезмәттәшлек итү турында 43 килешү төзегән.
Парламент комитетлары һәм Дәүләт Советы җитәкчесе исеменә 4,5 меңнән артык мөрәҗәгать кергән. Былтыргы саннан 44 процентка азрак бу.
Дәүләт Советы тарафыннан 93 закон кабул ителгән.

Сүзгә-сүз

Айдар АБДУЛХАКОВ, «Метроэлектротранс» җитәкчесе:

Маршрут челтәрен җайга салу һәм трамвай юлларын бөтен таләпләренә туры китереп, даими рәвештә карап тору үз нәтиҗәсен бирде: хәзер шәһәр халкы җир өсте электр транспортыннан ешрак файдалана. Моның файдасы табыш һәм пассажирлар саны артуда гына түгел, чакрымнар санында да күренә. Ягъни кешеләр ешрак һәм ераккарак йөри башлады.

(«Реальное время» электрон газетасындагы әңгәмәсеннән)

РОССИЯДӘ – ХАЛЫК САНЫ

2021 елгы илкүләм халык санын алу мәгълүматларына таянып, «Меркатор» компаниясе Россиядә яшәүчеләр арасында кемнәр күбрәк икәнен ачыклаган.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КАР ДАВЫЛЫ ЫЗГЫШТЫРА

Дүшәмбедән сишәмбегә каршы төндә газета хәбәрчесе Европадан шомлы хәбәрләр алды. Беренче хәбәр төн уртасында, 00.13 сәгатьтә килеп төште. Сербиянең оборона министры белдергүе иде ул. Сербиянең кораллы көчләре сугыш әзерлегенә китерелде, диелгән. Балкандагы телеграм-каналлар, бүген төнлә үк Сербия – Косово чигендә хәлләр кискенләшәчәк, дип шаулыйлар икән. Икенче хәбәр сәхәр вакытында, иртәнге дүртләр тирәсендә килде. Косово хакимиятләре дә үз хәрбиләрен тулы сугыш әзерлегенә китергәннәр. Тарих сабаклары тиз онытыла. Узган гасырның туксанынчы елларында гөлбакча кебек ил булган Югославия кан эчендә йөзде. Юл буендагы агачларда кеше башлары эленеп тора, дип язалар иде. НАТО блогы Сербияне рәхимсез рәвештә бомбага тотканнан соң гына чагыштырмача тынычлык урнашты. Вәхшәтне оештырган лидерлар Гаагада хөкем ителеп, читлеккә ябылдылар. Хәзер вазгыятьне тагын шуңа якынайтырга тырышалар. Ә бит төбенә төшеп карасаң, ике халык арасында сугыш чыгарырлык берни дә юк. Милли тәкәбберлек кенә бар.

Океан артында сугыштан башка да хәлләр киеренке. Анда кар бураны котырып, 700000 кеше утсыз калды. Корбаннар да бар. Аларның саны иллегә җитте, диделәр. Авыр хәл 12 штатта күзәтелә. Байден карлы штормга бәйле рәвештә Нью-Йорк штатында гадәттән тыш хәл игълан итте, хөкүмәтне штатка федераль ярдәм оештырырга чакырды.

Стихияле бәла-каза фонында Ак йорт белән Техас штаты арасында рәсми һәм рәсми булмаган конфликт кыза. Техас – Американың бәйсезлеккә дәгъва кыла торган штаты. Анда нефть байлыклары бик зур һәм, шуңа аркаланып, техаслылар һәрвакытта да үзләрен бәйсез тотарга тырышалар. Җитмәсә, агымдагы вазгыятьтә Техаста республикачылар хакимлек итә, федераль хөкүмәт демократлардан тора. Техас губернаторы Грег Эббот Мексикадан килгән йөзләп мөһаҗирне автобусларга утыртып, Вашингтонга озаткан һәм аларны вице-президент Камала Харрис өе янында ташлап киткәннәр. Вазгыятьтән ике як та сәяси очколар тупларга тырыша. Байден администрациясе Эбботны вәхшилектә гаепли, кышкы суыкта кешеләр тормышын куркыныч астына куйды, дип шаулый. Ак йортның пресс-секретаре Абдулла Хасан, Техас губернаторы балаларны салкында урамда калдырды, ди һәм: «Сәяси уеннар берни дә бирми, бары тик кешеләр тормышын куркыныч астына гына куя», – дип белдерә.

Үз чиратында Эббот гаепләүләрне кире кага, килеп туган хәлгә үзенең катнашы юклыгын әйтә. Әмма республикачылар, иммиграцион кризисны Байден администрациясе тудырды һәм шулар җавап бирсен, дип тә баралар.

Техаслылар социаль челтәрләрдә, кар буранын АКШ хөкүмәте ясалма рәвештә тудырды, безнең штат шуңа күрә авыр хәлдә калды, дип коткы тараталар. Америка сәясәтенең сәхнә артында әллә ниләр булып ята анда.

Россиядә

БАНКИРЛАР АКЧАНЫ КАЯ ЯШЕРӘ?

Соңгы ун елда Россиянең финанс кырында йөзләгән банк банкротлыкка чыкты, ябылды. Үзәк банк лицензиясез калдырган финанс оешмалары карынында триллионлаган сум акча юкка чыкты. Банк депозитларында акча тотучыларның теңкәсе корыды, кредиторлар акчаларын ала алмый җәфа чиктеләр. Бик күп эшмәкәрләр бөлде. Банкрот банкларның хуҗалары исә еш кына чит илләргә качып котылдылар. Күбесенең тимер пәрдәнең теге ягында ярыйсы гына тупланган маясы бар икән. Сүз триллионлаган сум акча турында бара. Депозит ияләренә Кертемнәрне иминиятләштерү агентлыгы (АСВ) акчаның закон тарафыннан билгеләнгән күләмен кайтарып бирә, билгеле. Бу еш кына Үзәк банк ярдәме белән башкарыла. Югалтулар акча басып каплана. Акча бастыңмы, инфляция котырына һәм, чынлыкта, банкротларның югалтуларын без, аларның махинациясендә бернинди дә катнашы булмаучылар, кибетләрдән кыйммәтләнгән товар алып түлибез.

Быелның 25 декабренә кадәр 377 финанс оешмасы юк ителгән. Аларның балансларында 3,2 триллион сум актив булган. Актив дип бездә кыйммәтле кәгазьләрне әйтәләр бит инде. Асылда ул активларның бәясе югарыда күрсәтелгән суммага тулмый, саткан очракта күпкә арзанрак бәягә генә сатып була. АСВ корпорациясенең генераль директоры, бөлгән банкларны юк итеп, алар балансындагы активларны 0,7–1 триллион сумга кадәр калдырачакбыз, ди. Калган акча (2 триллион сумнан артык) «киптерелү һәм иләнү» процессына дучар ителәчәк икән. Акча юк дигәнне аңлата бу.

Шулай да АСВ җан-фәрманга тырышып, берникадәр акчаны кире кайтара икән. Быелның 11 аенда 61 миллиард сум кайтарылган, мәсәлән. Ул суммага кемнәрнеңдер ирекле ярдәме, бурычлыларның бурычларын түләтү, бәясе берничә тапкыр төшерелеп сатылган активлар акчасы керә. Күрәбез: югалган акча белән кире кайтарылып алынган акча арасында җир белән күк аермасы. Киләсе елга, әйтик, 30–36 миллиард сум акчаны табарга ниятлиләр. Бөлгән финанс оешмаларының кредиторларына шул ысул белән барысы 70 миллиард сум акча кайтарылган. Эш шулай гына төгәлләнми әле. Кертемнәрне иминиятләштерү агентлыгы элек бөлгәннәрнең байлыгын эзләп мәшәкатьләнгәндә, банкротлар исемлегенә яңа банклар өстәлә. Соңгы ике елда 30 банк яфрак астына кергән, ягъни бөлгән. Шик юктыр ки, алдагы елларда да байлыкларын тишелгән куык кебек югалтып бетерүчеләр булачак. Зур финанс кризисы бусаганы атлавын истә тотканда, күбрәк тә булыр әле, мөгаен. Банкны юкка чыгару тиз генә башкарыла торган эш түгел, еллар үтә. Банклар гына түгел, башка финанс оешмалары да бөлә. Дәүләтнеке булмаган Пенсия фондлары, мәсәлән. Аларның исемнәре бар, халыктан җыйган акча бар, баланслары гына ул акчаны кире кайтарып бирерлек түгел. Бөләләр инде, нишләтәсең. Шунысы бар: бөлгән банк җитәкчеләре ач түгел, чит илгә качып өлгергәннәре мул гына тормышта яшәп ята. Шундый дүрт меңләп банкир бар дип беләм.

АҢЛАШУ ҺӘМ БЕРЛӘШҮ ЕЛЫ

«Теләкләр чыршысы» кысасында Фәрит Мөхәммәтшин Даниэль исемле егетнең хыялын тормышка ашырды. Малай поезд йөртүченең кабинасына утырырга теләгән икән. Үзе Нурлатта яши. Даниэльнең теләге «Нурлат» тимер юл станциясе хезмәткәрләре ярдәмендә чынга ашты.

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Акчаның җиткән чагы юк аның, ул сиңа-миңа да, гаиләгә дә, дәүләткә дә җитми, – диде Фәрит Мөхәммәтшин, уенын-чынын бергә кушып. – Планнарыбыз зур, аларны инде корып куйдык. 27 млрд сум күләмдә акча җитми әлегә. Грантлар алырга исәп. Федераль үзәк тә ярдәм итми тормас. Курыкмагыз, кулга-кул тотынышып эшләгәндә, бу бурычларны да үтәрбез.

Сүзе түгел, үзе мөһим

Әлбәттә, Президент атамасын «Рәис» дип үзгәртү мәсьәләсен телгә алмый мөмкин түгел иде. Фәрит Мөхәммәтшиннан күбрәк мәгълүмат алырга теләде журналистлар. Әмма Дәүләт Советы Рәисе серләрне чишәргә ашыкмады.

Шулай да, җитди телгә күчсәк, Фәрит Мөхәммәтшин бу гамәлнең җентекләп уйланган булуын әйтте.

– Федераль үзәкнең тискәре җавабы булыр дип көтмибез. Без кушылганча эшләдек – республиканың югары вазыйфаи заты атамасын закон кысасында үзгәрттек. Конституциядә хәзер «президент» атамасы юк. Без федераль үзәккә каршы килмәдек, – диде ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Безнекеләр – БМОда

Татарстан халыклары ассамблеясына Берләшкән Милләтләр Оешмасының Икътисадый һәм социаль советы каршындагы консультатив статусы бирелгән. БМО эшендә катнашу мөмкинлеге бирүче статус бу. Оешма белгечләре билгеләп үткәнчә, ассамблея туплаган тәҗрибәгә, шул исәптән аның дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары, яшьләр оешмалары белән берлектә эшләү тәҗрибәсенә БМОда ихтыяҗ зур.

«Татарстан халыклары ассамблеясы утыз еллык эшчәнлеге дәверендә республиканың иҗтимагый-сәяси тормышында катнашучы абруйлы оешмага әйләнде, составындагы милли-мәдәни оешмалар саны артты, муниципаль берәмлекләрдә филиаллары барлыкка килде, яшьләр канаты актив төстә эшли – чит илләрдән килгән студентларны безнең мохиткә җайлаштыру мәсьәләләрен игътибар үзәгендә тотып килә, – дип билгеләп үтте Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясы советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, БМО кабул иткән карарны аңлатып. – Ассамблеяның бай эш тәҗрибәсе, күпмилләтле хәрәкәтнең республикада хакимиятнең барлык баскычларында карарлар кабул итүдә катнашуы чит илләрдә зур кызыксыну тудыра. БМО Икътисадый һәм социаль совет каршындагы консультатив статусын алуга гариза тапшыру халыкара делегацияләр белән очрашуларда безгә күп тапкыр тәкъдим ителде».

Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, халыкара оешмада консультатив статусын алу төбәкләргә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру буенча тәҗрибә алышу, шулай ук Россия халыкларының традицион кыйммәтләренә этәргеч бирү мөмкинлеге бирә. Безнең республика һәм тулаем Россия өчен чит илләрдәге коллегаларыбыз белән берлектә эшләүгә яңа мәйданчык ачылды, – дип басым ясап әйтте парламент башлыгы. – Без үзебезне ишетсеннәр өчен мөмкин булганның барын да эшләргә тырышачакбыз».

Берләшкән Милләтләр Оешмасының Икътисадый һәм социаль советы каршындагы консультатив статусы хөкүмәтнеке булмаган оешмаларга (НПО) бирелә. Консультатив статус – хөкүмәтнеке булмаган оешмалар белән Берләшкән Милләтләр Оешмасы арасындагы мөнәсәбәтләрне рәсми төстә раслау ул. Мондый иҗтимагый оешмалар БМОның рәсми утырышларында катнаша, язмача һәм телдән белдерүләр белән чыга. БМОның вазыйфаи затлары, БМО мәйданчыгында башка НПО вәкилләре белән очрашуларда катнаша ала.

Эштән соң ял кирәк

Нәтиҗә

Яңа елга аяк басарга санаулы көннәр калып бара. Социаль яклау өлкәсендә нинди эшләр башкарылды? Кемнәрне нинди яңалык көтә? Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова журналистлар белән очрашып, елга нәтиҗә ясап, киләсенә планнар корды.

– Республикада ел башында тулы көн эшләмәүчеләр күп иде. Казан, Алабуга, Зәй, Чаллы шәһәрләрендә аларның саны 18 меңгә җитте. Тора-бара күбесе тулысынча эшкә урнашты. Бу ковид чорындагы чикләүләргә дә бәйле. Күп кенә оешмалар санкциягә эләгеп тә, эшчеләр саны кыскарды. Әмма без хезмәт базарындагы хәлләрне яхшырту өчен, күп кенә ярдәм чаралары хисабына, эшсезләрне эшле итә алдык, – ди министр.

Дәүләттән нинди ярдәм чаралары күрсәтелгән соң? 110 оешма 1200 кешене иҗтимагый эшләргә җәлеп иткән. 36 оешмада тулы көн эшләмәүче 15,4 мең хезмәткәрнең хезмәт хаклары арттырылган, 3,8 мең кеше яңа һөнәр үзләштергән. Тагын бер яңалык: 30 яшькә җитмәгән, эш таба алмаган, кыскарту алдында торган кешеләргә дәүләт эш субсидиясе бирә башлаган. Алар эшкә урнашкан очракта, дәүләт өч яшәү минимумы күләмендә акча бирә. Кеше аның беренчесен – эшкә кереп бер ай узгач, икенчесен – 3 айдан, өченчесен алты айдан ала.

Министр әйтүенчә, имин булмаган, авыр хәлдә калган гаиләләргә дә «кармак» бирә алар. Ягъни эшен дә табып бирә, дәүләттән тиешле барлык акчаны да түли. Бер ягы бар – син эшләргә тиеш.

Быелның 11 аенда 7,3 мең социаль контракт төзелгән. Аз керемле 16,3 мең гаилә дәүләт ярдәме белән үз эшен башлап җибәргән. 2022 елга кадәр авыл җирендә яшәүче авыр хәлле гаиләләр социаль контракт төзи алмаган. Сәбәбе – мохтаҗлыкны исәпләгәндә пай җирләре булу комачау иткән. Хәзер аны исәпкә алмый башлаганнар. Шуннан соң авылдагы 600 гаилә дәүләт ярдәме алган. Дәүләт андыйларга, үз эшен башларга дип, акча биргән. Ул акчаны кайтарасы булмый. Бер генә шарт: аз керемле булган гаиләнең кулында нинди эш башлаячагы хакында бизнес планы булырга тиеш. Шәхси эшмәкәрлекне башлап җибәрүчеләргә бер тапкыр 350 мең сум, үз хуҗалыгында маллар тотучыларга 200 мең сумга кадәр ярдәм каралган.

Эш турында сөйләшкәч, илдәге хезмәт хакларына да тукталдылар. 2022 елның ун аенда республикадагы уртача хезмәт хакы 50 мең сумнан артып киткән. Әмма шул вакытта аз хезмәт хакы алучылар да бар әле.

– Безнең максат – хезмәт хакларын арттырып, халыкның тормышын яхшырту. 15 декабрь көнне Россия Президенты Владимир Путин да 2023 елга хезмәт хакларын арттыру бурычы куйды. Татарстанда ел саен минималь хезмәт хакы арттырыла. Моңа кадәр 15279 мең сум булса, 1 гыйнвардан 16242 мең сумга җитә, – ди министр.

Эльмира Зарипова бердәм пособие хакында да сөйләде. Аңа керемнәре яшәү минимумыннан ким булган гаиләләр өметләнә ала, диде. Кыскасы, үз эченә алты төр ярдәмне керткән бу пособие бала ана карынында чакта ук түләнә башлап, аңа 18 яшь җиткәнче дәвам итә ала.

Министр республика халкына Яңа ел белән котлавын да җиткерде. Без исә аның бәйрәмне ничек каршылыйсын сораштык.

– Бездә бер гадәт бар. Яңа ел бәйрәменә барлык туганнар килә. Ике атна ялда 1000 пилмән ясап куйдым инде. Уларым, бәйрәмдә аукцион уздырыйк, дигәч, аңа әзерләндек, – ди ул. – Бездә бәйрәм берничә сәгатьтән соң эшлекле сөйләшүгә әйләнә. Туганнар дәүләтнең ярдәм чараларын сораштыра, тәнкыйди фикерләрен дә җиткерәләр. Юл акчасы бетерелгәч тә, керемнәр исәпләнгәндә, милек һәм җир саналгач та канәгать булмауларын әйттеләр. Тик берни эшләп булмый. Дәүләт эшен шәхси мәнфәгатьләр белән бутарга ярамый.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

2022 елда Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен бирү турында

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләре комиссиясе тәкъдимнәрен карап, **карар бирәм**:

2022 елда Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен һәм «Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премиясе лауреаты» исемен түбәндәгеләргә бирергә:

1. «Татарстан Республикасында бөртекле культуралар орлыкчылыгының инновацияле системасын булдыру һәм файдалануга кертү» хезмәте өчен:

Еров Юрий Васильевичка, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, доцент, «Татарстанның элиталы орлыклары» бөртекле культуралар орлыклары җитештерү ассоциациясе генераль директоры, хезмәтнең җитәкчесенә;

Габдрахманов Илдус Харис улына, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, доцент, «Агропроект» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директорына;

Грачев Владимир Александровичка, «Кыят» ачык акционер җәмгыяте генераль директорына;

Зәйнуллин Шаһит Әминбай улына, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, «Татарстанның элиталы орлыклары» бөртекле культуралар орлыклары җитештерү ассоциациясенең технологияләр һәм орлыкчылык бүлеге башлыгына;

Имамиев Илдар Мәгъсүм улына, «АГРОАЛЬЯНС РИА» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коммерция директорына;

Мәүлин Вәзир Рәкыйп улына, «Татарстанның элиталы орлыклары» бөртекле культуралар орлыклары җитештерү ассоциациясе баш бухгалтерына;

Нуруллин Эльмас Габбас улына, техник фәннәр докторы, «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе профессорына;

Прокофьев Николай Петровичка, «Чистай орлыклары» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директорына.

2. «Нефть катламнарының һәрберсен аерым-аерым бер скважина ярдәмендә бер үк вакытта эксплуатацияләү ысулларын эшләү һәм сәнәгатьтә файдалануга тапшыру» хезмәте өчен:

Гарифов Камил Мансур улына, техник фәннәр докторы, профессор, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Татарстан фәнни-тикшеренү һәм проектлау нефть институты «Скважиналарны эксплуатацияләү һәм төзекләндерү» бүлеге башлыгы, хезмәтнең җитәкчесенә;

Артюхов Александр Владимировичка, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе Нефть һәм газ чыгару департаментының Нефть һәм газ чыгару идарәсе башлыгы урынбасарына;

Балбошин Виктор Александровичка, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Татарстан фәнни-тикшеренү һәм проектлау нефть институты «Скважиналарны эксплуатацияләү һәм төзекләндерү» бүлегенең скважиналарны эксплуатацияләү секторы мөдиренә;

Воронин Николай Анатольевичка, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Татарстан фәнни-тикшеренү һәм проектлау нефть институты «Скважиналарны эксплуатацияләү һәм төзекләндерү» бүлеге әйдәүче инженерына;

Глуходед Александр Владимировичка, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Татарстан фәннитикшеренү һәм проектлау нефть институты «Скважиналарны эксплуатацияләү һәм төзекләндерү» бүлеге нефть чыгару техникасы һәм технологияләре лабораториясе мөдиренә;

Кадыйров Альберт Хәмзә улына, техник фәннәр кандидаты, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Татарстан фәнни-тикшеренү һәм проектлау нефть институты «Скважиналарны эксплуатацияләү һәм төзекләндерү» бүлеге катлаулы скважиналарны эксплуатацияләү һәм төзекләндерү лабораториясе мөдиренә;

Рахманов Илһам Нух улына, техник фәннәр кандидаты, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Татарстан фәнни-тикшеренү һәм проектлау нефть институты «Скважиналарны эксплуатацияләү һәм төзекләндерү» бүлеге скважиналарны төзекләндерү секторы мөдиренә;

Фадеев Владимир Гелиевичка, техник фәннәр кандидаты, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Оештыру ягыннан үсеш идарәсе башлыгына.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 26 декабрь
№ ПУ-923

Шифаханәдә дәваланып кайткан Кукмара тракторчылары, сыер савучылары әнә шундый нәтиҗә ясаган. Җир казып, мал-туар арасында кайнашып яшәргә генә димәгән бит. Авыл кешесенә дә ял кирәк.

КАДЕРЕБЕЗ БАР ИКӘН!

– Быел үзебезнең эшчеләрне шифаханәгә җибәрә башладык. Барлыгы 24 юллама бирдек. Арада сыер савучы, бозау караучы, тракторчы, төзүче, тимерче һәм башка белгечләр дә бар. Барлык чыгымнарны агрофирма каплады. Алга таба да эшчеләребезнең сәламәтлеген кайгыртуыбызны дәвам иттерәчәкбез, – ди Кукмара районының «Восток Агро» агрофирмасының кадрлар бүлеге җитәкчесе Алсу Ишмөхәммәтова.

Чишмәбаш авылы егете 46 яшьлек Ришат Шакиров, шифаханәгә юллама алгач, аптырап калган.

– Юллама Кыш бабай күчтәнәче кебек булды. Эшчеләрне кадерләү дигән сүз бит бу. «Без дә бар икән бу дөньяда», – дип куйдык. Җитәкче юллама бирмәсә, үзегез беләсез, без авылдан мәңге ял итәргә чыгып китә алмыйбыз. Эшкә бер башны тыккач, аннан тиз генә чыга белмибез. Ял итеп кайткач, бөтенләй икенче. Кәефләр шәп, эшлисе генә килеп тора, – ди көр күңелле Ришат.

Аның җәмгыятьтә тракторчы булып эшли башлавына – ун ел. Аңа кадәр төрле оешмаларда хезмәт куйган. Тик тракторчы эше күңеленә аеруча якын икән. «Аллага шөкер, трактор бар дип, иртәнге сәгать 5тә эшкә чыгып китәм. Техника миңа көч бирә. Эшемнән тәм табып яшим, – ди Ришат.

Купка авылында яшәүче Нияз Шәрәфиев исә 27 ел трактор йөртә. 17 яшьлек егет, Янил училищесының икенче курсын тәмамлагач, техникага утырган, шуннан бирле аннан төшкәне юк. Башта «ДТ»ны иярләсә, соңгы елларда фермада «Беларус» белән малларга азык тарата. Бүген инде ул алдынгы механизаторлардан санала. Аның фотосы Мактау тактасында эленеп тора. Шифаханәгә үз гомерендә беренче тапкыр баруы икән.

– Төрле җитәкчеләр белән эшләдек. Руслан Корбанов эшебезне бәяли белә. Хезмәт хакын да вакытында бирә, – ди Нияз. – Эшчеләрнең сәламәтлеген дә кайгырта. Менә Мари Иленнән ун көн ял итеп кайттык. Дәвасы да, шартлары да ошады. Еракка чыгып ияләнмәгәч, эш тә, авыл сагындырды анысы.

Нияз тормышын авылдан башка күз алдына да китерә алмый. Бервакытта да читкә китү уе булмаган. Шәһәргә кунакка барса да, шау-шудан туеп, тизрәк Купкага кайту ягын карый. Җирдә казынып яшәргә күнеккән ул. Шәрәфиевләрнең үз җирләре бар. Басуга чыгып эшләүне Нияз бер рәхәткә алыштырмый. Тракторчы булуына да үкенми: «Элеккеге техника белән чагыштырганда хәзергесе көчле. Әмма эш тәртибе үзгәрми: шул ук техника, аны сүтеп, төзекләндереп торасы. Ә мазутка буялу-буялмау үзеңнән тора. Пычрак та, чиста итеп тә эшләп була», – ди ул.

Без шалтыратканда, Зур Сәрдек авылы сыер савучысы – 47 яшьлек Минзилә Касыймованың хезмәттәшләре белән ялдан кайтып килеше иде. 15 ел сыер сауган ханым ял йортына беренче тапкыр барган. Диңгезне күрмәсә дә, Тозлы күлдәге рәхәтлекне кичергәне бар.

– Шифаханәдә бик яхшы дәваладылар. Бөтен колхозчылар да сөенде, – ди ул.

Минзилә Касыймова моңа кадәр Чишмәбаш фермасында сыер сауса, август аенда агрофирмага күчкән. Аның әйтүенчә, мегафермада эшләү җиңелрәк. Аерма – җир белән күк арасы, ди. Якты, чиста. Телисең икән, чәй эчеп, керләр юып була. «Эш өч сменада оештырылган. Беренчесендә иртүк сәгать 4 тә чыгып китәбез. Атнага бер көн ял. Барысыннан да риза», – ди Минзилә.

Сәрия МИФТАХОВА

РӘШӘЛЕ ДӨНЬЯ

Премьера

Камал театрында премьера. Мәхәббәт – рәшәме, чынбарлыкмы? Тамашачы театрдан әнә шул турыда уйланып кайтып китте. Әмирхан Еникинең «Рәшә»се Камал театры сәхнәсенә беренче тапкыр күтәрелде. Аны яшь режиссер Айдар Җаббаров куйды.

«Татар-информ»

Спектакльдә вакыйгалар Әмирхан Еникинең сугыш афәтен кеше күңеленә тирән үтеп керерлек итеп сурәтләгән хикәясеннән башлана. «Рәшә» спектакле геройлары «Бер генә сәгатькә» спектаклен куя.

«Рәшә»нең үзенә күчик. Ул 1962 елда язылган. Вакыйгалар 1943–1945 елларны Казан шәһәрендә бара. Сюжеты гади: сәүдә хезмәткәре һәм филармония җырчысы кышкы салкын көндә очраклы рәвештә тимер юл вокзалында очраша. Эшлекле ирнең сәүдә нокталары ревизиясе белән республика авылларының берсенә барышы була. Чибәр туташ та концерт бригадасы составында шул ук авылга ашыга. Кыз шунда ук ирнең игътибарын туры, кыю карашы һәм йомшак елмаюы белән җәлеп итә. Күркәм кыяфәтле, тыйнак кына ир дә кызда ышаныч уята…

Спектакльнең төп декорациясе – зур-зур тимер складлар. Гади генә шул складлар вакыйганың бөтен фаҗигасен күрсәтә дә инде. Чөнки спектакль геройлары һәрвакыт шулар арасында: мөһим эшләр, карарлар хәл итәләр, урлашалар, елыйлар…

Санап, хисап белән генә эш иткән, озак уйлап, «дөрес» яшәргә өйрәнгән Зөфәр (Алмаз Борһанов) белән хыялый, нечкә күңелле Рәшидә (Татарстанның атказанган артисты Гүзәл Шакирова) мәхәббәте нидән гыйбарәт соң? Зөфәр Рәшидәнең «беренче караштан ук бик самими һәм бик табигый тоелган» дөньясын үз итә. Рәшидәнең дә «акыллы, тыйнак, әдәпле» Зөфәргә йөрәге якыная. Тик Рәшидәнең хыяллары үз бәхетен «матди һәм рухи бәйсезлек»тә күргән ирнеке белән кисешми.

Зөфәрнең «Эшенә күрә әҗере бар икән, аңа шул җиткән. Һәркемнең үз исәбе – дөньясы шул!», «Чукынган заман… курыкмыйча, яшеренмичә бер генә нәрсә дә эшләп булмый бит!», «Исәп белән яшәргә кирәк» дигән сүзләре аның тормыш турындагы бөтен фәлсәфәсен ачып сала. Зөфәрнең кемлеге, нииндилеге аның үзүзен тотышы, характеры аша ачыла. Әйтергә кирәк, Алмаз Борһанов аны тамашачыга оста җиткерә. Зөфәрнең аз сүзлелеге, бар әйбергә дә исәп белән каравы – һәрвакыт галстук, үтүкләнгән костюм-чалбар киюе, астан каравы, йөзенә кепкасын төшереп йөрүе кебек детальләрдә чагыла.

Рәшидә исә – эчкерсез, чын күңелдән яраткан кешесен үзе кебек саф күңелле дип уйлаучы хатын-кыз. Ирен югалткан, ачлы-туклы яшәү михнәтен тойган сәнгать кешесен тамашачыга тәэсирле итеп җиткерә алган Гүзәл Шакированы да аерым билгеләп узарга кирәк.

Зөфәрнең тормышы гына түгел, мәхәббәте дә исәп-хисапка корылган. Рәшидәне яратса да, «кемнәндер калган җилбәзәк артистка»ны үзенә тиң яр булырга лаек дип тапмый ул.

> Зөфәр өчен тормышның Рәшидәле ягы рәшә генә булып чыга (табигать күренеше буларак, рәшә – эссе һавада уйнаклаган шәүлә): «Тип-тигез дала түрендә ялтырап яткан күл ачыла. Чын күл бу, хәтта җем-җем уйнаклаган вак дулкыннарына кадәр күренә. Менә шул күлгә карап барасың, барасың, ләкин күпме генә барсаң да, барып җитә алмыйсың. Чөнки ул юк, ул рәшә генә, коры далада алдап-уйнаклап югалган эссе кайнар шәүлә генә».

Кариев театры баш режиссеры Ренат Әюпов спектакль режиссеры авторны ача алган дигән фикердә.

– Актерларның уйнау манерасы, сценография, музыка, костюмнар – бөтенесе дә Әмирхан Еникине ача. Шуның кадәр профессиональ дәрәҗәдә эшләнгән. Героиня да туры килерлек итеп сайланган. Прозаны сәхнәләштерү бик авыр. Тик никадәр катлаулырак булса, шуның кадәр кызыграк та бит ул. Һәм Айдар бу уңышка ирешкән. Динамика җитеп бетми, әлбәттә, спектакль сузылган. Режиссер вакыт буенча компактрак җыйган булса, тамашачы тагын да яратыр иде. Яшь буын белән олы буыннарны берләштереп эшләгән режиссерларны бик хөрмәт итәм. Ике-өч буынның бер сәхнәдә булуы бер-берсен тулыландырып тора, – ди режиссер. – Әмирхан Еники белән кызыксынам, чөнки үзебез дә киләсе елга аның «Матурлык» хикәясен сәхнәләштерергә җыенабыз. Бу әсәрне куярга башкорт режиссеры Айрат Абушахмановны чакырдык. Проза әсәрләре һәрвакыт татар театрын тукландырды. Безнең театралларны, режиссерларны, актерларны үзебезнең милли проза әсәре коткара. Әмирхан Еникигә сәхнәдә юл ачылды дип саныйм.

Татарстанның атказанган табибы Руфина Фәттахова спектакль уңышлы дигән фикердә:

– Тулаем алганда, спектакль миндә начар тәэсир калдырмады. Бары тик сузынкы булуы белән генә азрак арытты. Шунысы сөендерә: анда Әмирхан Еники югалмаган. Әмма музыка белән баетасы иде аны. Ә заманча музыка урыны белән ачуны китерде хәтта. Эпизодик рольләрдә олы буын артистларын, әйтик, Рузия Мотыйгуллина, Илдар Хәйруллинны күрү аеруча сөендерде. Сәхнәдә буыннар алмашын күрү, гомумән, сөендерә. Ә режиссерның проза әсәренә алынуы – үзе үк батырлык. Киләчәктә аңа уңышлар телим.

Сүз уңаеннан, спектакльне Әмирхан Еникинең кызы Флера Карташова-Еникеева да карады. Ул да режиссер эшеннән канәгать калуын әйтте:

– Үзенең карашы булган талантлы егет булуы әллә кайдан күренеп тора. Миңа аеруча «Бер генә сәгатькә» әсәрен ничек сәхнәләштерүләре һәм шул күренеш белән «Рәшә»не оста бәйләп алып китүләре ошады. Спектакль яшьләргә юнәлтелгән һәм алар алдына бик күп сораулар куя. Мин бары тик уңышлар гына телим.

Курамшин карт ролен башкаручы Татарстанның халык артисты Әсхәт Хисмәт исә спектакльдә барган вакыйгаларны бүген дә актуаль дип саный.

– Курамшин карт – хәзерге риелтор кебек кеше. Зөфәр мескен бабайны алдап, төп башына утырта һәм аңа моның өчен берни дә булмый. Дөньяда хәзер дә андыйлар күп. Бүгенге көндә бик актуаль. Шул күренеш белән Айдар аның бөтен фаҗигасен ачып салды, – ди Әсхәт абый. – Әмирхан Еникинең «Рәшә» әсәре – татар театры сәхнәсендә куелган әсәр. Элек аны күчмә театрда инсценировка авторы – Марсель Җаббаров белән Празат Исәнбәт куйды. Рәшидә ролендә Исламия Мәхмүтова иде. Безнең спектакльдә Зөфәрне тискәре герой итеп күрсәттек, ә анда мәхәббәт уйнадылар.

Заманында шактый бәхәсләр һәм каршылыклы фикерләр уяткан «Рәшә» повесте сәхнәдә үзенчәлекле табигый яңгыраш алды. Монда геройлар да, сәхнәдәге мохит тә – Еникинеке. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәт, намус, байлык, әхлакый бозыклык, кеше булып кала белү… Узган гасырда язылган әсәрнең төп, үзәк проблемасы хәзер дә актуальлеген югалтмый. Хәтта аны тагын да фаҗигале итә.

Ләйсән САФИНА

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Сумнар белән үлчәнми

Метродан чыгып, беркадәр атлауга, миңа туп-туры карап торучы утыз биш-кырык яшьләр тирәсендәге ирне шәйләп алдым. Бер мизгелгә генә карашлар очрашты да ул миңа таба килә башлады. Мондый нәрсәләрне күргәнем бар инде. Нидер сораячак хәзер, я тәмәкесе юктыр, я баш төзәтергә ун сум җитми калгандыр.

Элегрәк шулай туры карап торучы егетләр килеп бәйләнә дә торганнар иде, сораганнарын бирмәсәң, я сугып әйләндерсәң, кайсыдыр почмаклардан әшнәләре чыгып уратып ала, я качып котыласың, я бәргәләп китәләр. Хәзер алай кыланучылар юк бугай инде. Ничек кенә булмасын, урамда күзеңә туп-туры карап торган кеше сиңа файда китерер өчен йөрми.

Бу адәм исереп азып-тузып йөрүчегә тамчы да охшамаган иде. Сугыш чукмары да, кеше талаучы да түгел. Сәрхушнең бөтен гамәле йөзенә чыккан шикелле, таларга җыенучының да ниндидер үзенчәлекле сыйфатлары була, шулар аның күзләренә чыга, йөзенә сибелә, атлап йөрешеннән, үз-үзен тотышыннан сизелә. Игътибарлап күзәтер мөмкинлегең табылса, әшнәләре чама белән кайсы тирәләрдә яшеренгәнлеген дә сизә аласың.

– Гафу итегез, – диде ул, тавышына ялвару ачысы чыгарып. Сүзләре генә түгел, җиргә кадалган күзләре дә, күз төбенә җыелган дүңгәләкләре дә, маңгаена яткан тирән сырлар да – бөтен кыяфәте аның ихлас күңелдән түбәнчелек белән кичерү соравын сөйли һәм аны гафу итмәү мөмкин түгел иде. Мин баш кагып куйдым. Буталчыграк итеп озак маташтырды инде ул, ә кыска гына әйтсәң, болай була: моның сумкасын урлаганнар, акчасы да, телефоны да, карталары да шунда калган. Уфага кадәр кайтырлык акча кирәк, кайту белән кире җибәрәчәк.

Мин аңа тагын бер тапкыр баштанаяк күз йөрттем. Еламый гына инде, бахыр. Аягыңа егылып, тезләреңне кочаклап алырдай булып басып тора. Мескенлекнең үзе шикелле. Аның хәленә калгач, башыңны күккә чөеп, авызыңны колагыңа җиткереп йөри алмыйсың инде. Горур булу өчен сәламәтлек, көч, аң-белем, акыл гына җитми ул, азрак акча да таләп ителә. Башыңа бәла төшкәндә әллә кем була алмыйсың. Мин моны бик яхшы беләм, чөнки үземнең дә нәкъ шул хәлдә калганым бар иде…

Күптән булды инде бу хәл. Ул чакта кәрәзле телефоннар да, акча карталары да, башка рәхәт нәрсәләр дә юк иде әле. Бер билгеле артистның гастрольләре белән йөргәндә, концертларсыз ике-өч көн туры килде, мин шул арада авылга кайтып, хәл белешеп килим дип, аерылып калдым. Нинди шәһәр икәне мөһим түгел инде, ул дәвердә бөтенесендә дә шундыйрак күренеш табыла иде. Турыга гына автовокзалга чыгарга теләп, бер парк аша барам. Бер кулда – концерт костюмнары салынган асылмалы чехол, икенчесендә – үземнең киемнәр, өйгә алынган күчтәнәчләр. Авыр гына, кыскасы… Шулай сабыр гына атлап барганда… Мин аларны башта йөгерергә чыккан спортчы егетләр дип уйладым. Сокланып та куйдым әле хәтта. Минем яннан бер әйләнеп уздылар да икенчесендә каршыга килеп бастылар һәм, нәрсәдер уйлап өлгергәнче, нидер сиптерделәр. Ул вакытларда «нервно-паралитический газ» дип йөртелә торган нәрсә популяр иде. Шул икәнен чамаладым инде, тиз генә йөкне куеп каршылык күрсәтергә әзерләндем. Уң аякның күтәрелә башлаганын хәтерлим… Аннан соң мине ниндидер дулкын бу дөньядан юып төшерде…

Бер мәлне уянып киттем. Агачлык буйлап каядыр китеп барам. Үземнең кая барганны да, нишләп йөргәнне дә аңламыйм. Кулда берни дә юк. Сумкалар гына түгел, хәтта сәгать тә юк. Беркадәр йөргәч, баш мие аз гына хәрәкәтләнә башлады инде. Мин үземнең нишләп йөрүемне чамаладым. Теге егетләр дә искә төште. Сумкалар да. Документлар кесәдә иде, анысына тимәгәннәр. Бер тиен акча калмаган. Ә кайтырга кирәк.

Яңадан мәдәният сараена барып, акча сорап торсаң булыр иде. Анда барсаң, ниндидер җай табыласы булган. Тик ул вакытта мин бу хакта уйламадым. Башка килмәде. Бөтен ният тизрәк автобуска утырырга да бу каһәрле шәһәрдән чыгып качарга иде. Кассада бик кызганган кыяфәт белән баш кага-кага тыңладылар да билет бирмәделәр. «Попутка»га чыгып кара, диделәр. Тик анда барыр өчен дә акча кирәк.

Мин озак кына буталып йөрдем. Турыдан-туры соранмасам да, кемнәргәдер хәлне аңлатырга маташтым. Бик бирелеп тыңласалар да, акча биреп торырга уйлаган кеше табылмады. Аптырагач, бер кибеткә кереп мөлаем гына бер ападан акча сорадым. Ул башта сәерсенеп китте, аннан мине энә күзеннән үткәреп озак кына карап торды. Һәм касса ягына атлады. Милиция чакырса да барыбер иде. Качмадым. Бераздан ул әйләнеп килде дә сораган сумманы кулга тоттырды:

– Алдама, акчаның бик кирәк вакыты, – диде ул, күземә туп-туры карарга тырышып. – Менә бу кәгазьдә кая күчерергә кирәклеге язылган. Исән-сау кайтып җит. – Һәм елмайгандай итте. – Монысын да урлатма инде…

Мин авылга исән-сау кайтып җиттем дә икенче көнне үк теге апага акча күчердем. Чүт кенә артыграк итеп. Кешеләрнең әйбәтлегенә ышаныч тудырганы өчен иде анысы.

Менә бу адәмне очраткач, шул вакыйга искә төште. Һәм әллә ниләр төпченеп тормыйча гына бер меңлекне кулына тоттырдым. Бәлки, ул чынлап та бәлагә тарыгандыр. Бәлки, кешеләрнең әйбәтлегендә акча эшләп йөрүче аферисттыр. Белмим. Кешенең эчен ачып карап булмый бит…

Ул бик зур ихласлык белән рәхмәт укыды-укыды да йөгерә-атлый тукталышка ашыкты. Алган акчасын ничек кайтарырга икәнен дә сорамады. Бәлки, шатлыгыннан онытып җибәргәндер. Ә аферист булса, эчен тотып: «Лох!» – дип көлгәндер. Ләкин эш анда түгел… Эш менә нәрсәдә… Аферист миннән бер мең сум акча алды. Ул аңа бер көнгә дә җитмәячәк – тотып бетерәчәк. Моннан ул баемый, мин бөлмим. Ә чынлап та бәлагә тарыган адәм икән, дөньяда яхшы кешеләр дә барлыгына ышанычы уянды. Бу аның гомере буена җитәчәк. Акча сумнар белән генә үлчәнми ул…

ӨМЕТ

Адәм баласы гомере буена ниндидер өмет белән яши. Бала чагында тизрәк үсәсе килә, аннан ниндидер уңышларга ирешү теләге белән яна. Күпләрне ил күләмендәге мәшәкатьләр дә борчый башлый.

Безнең өчен иң истә калганы Горбачевның илне үзгәртеп кору идеясе булды. Мин үзем илебезнең демократик, чын федератив дәүләт булуына ышанасым килеп яшәдем. Тик, ни кызганыч, Горбачев өметебезне аклый алмады. Курыкты. Шуның белән сәяси уенны оттырды. СССР таркалды. Илебезнең таркалуында аны гаепләргә тырышучылар бар. Ләкин бу һич кенә дә дөреслеккә туры килми. Чөнки ил, большевистик империя буларак, инде череп беткән, юкка чыгу юлына баскан, Горбачевның якын кешесе Анатолий Черняев язганча, аның яшәү ресурслары беткән була. Аны үзгәртеп кору сәясәтен тулысы белән тормышка ашырып, конфедератив дәүләткә әверелдереп кенә саклап калып булыр иде. Горбачевның уенда, ул үзе әйткәнчә, андый вариант та булган. Ләкин ул уй аңа соңарып, властьны югалткач кына килгән. Тарихта беркайчан да соңга калырга ярамый.

Тарихны кайтарып булмый. Ләкин кайтарырга тырышучылар юк түгел. Аларның берсе – Думадагы Кырым депутаты Михаил Шеремет. Ул бүгенге шартларда, Көнбатыш илләре Россиягә янаган, аңа куркыныч тудырган көннәрдә СССРга охшатып, республикаларның ирекле рәвештә берләшүләре кирәк, дип саный. Аныңча, күрәсең, бу берләшү республикаларның суверенлыгын ныгыту чарасы булачак. Ләкин бу кешегә һәм аның кебекләргә дөньяга ачык күз белән карау җитми. СССРның элеккеге республикалары һич кенә бәйсезлекләреннән ваз кичәргә җыенмый. Киресенчә, Россиядән ераграк торырга тырышалар. Моңа хәтта Россиягә якын, формаль рәвештә аның белән бер дәүләттә саналган Белоруссия дә әзер түгел.

Россия кабул иткән Декларациядә автономияле республикаларның вәкаләтләре берничек тә билгеләнмәгән. Шунлыктан моңа җавап итеп, Татарстан 1990 елның 30 августында үзенең суверенлык Декларациясен кабул итте. Аңа ияреп, Россиянең 40ка якын субъекты шул юлга басты. Тик алар, Татарстаныкыннан аермалы буларак, үзләрен Россия субъекты итеп күрсәттеләр. Ә Татарстан Башкортстанның безнеке кебек Декларация кабул итүенә өмет баглаган иде. Мин шуннан соң Минтимер Шәймиевнең: «Союзникларсыз калдык бит», – дип уфтанганын хәтерлим. Уфтанырлык та шул, чөнки Татарстан тулы суверенлык документын кабул иткән берддәнбер республика булып калды. Моны таныту өчен, Россия белән сөйләшүләрне дә ул берүзе алып барды. Һәм Россия җитәкчеләрен күндерә дә алды. Суверенлыгыбызны яклау референдумында республика сайлаучыларының 61,4 проценты куелган сорауга уңай тавыш бирде. Шуның нәтиҗәсендә республиканың халык теләгән Конституциясе кабул ителде.

Дөрес, шактый мәҗбүри чигенүләргә барып, аңа үзгәртүләр кертелде. Ләкин анда Татарстанның суверен дәүләт икәнлеге акка кара белән язылган. Ә бу исә – киләчәктә шуңа таянып, аны баетып булуга өмет бар дигән сүз.

Бүген исә дөнья, шул исәптән Россия дә билгесезлектә яши. Иртәгә нәрсә буласын берәү дә белми. Моңа кадәр татарлар Россиянең иминлеген, аның бөтенлеген саклап калуга зур өлеш кертә килделәр. Бүгенге һич кенә дә җиңел булмаган шартларда да аларның мөмкинлекләре юк түгел. Ул үзендә чыгарыла торган нефтьнең 80 процентын үзе эшкәртеп, продукция белән сәүдә итә. 141 ил белән төрле рәвештәге мөнәсәбәтләр урнаштырып яши. Аның элемтәләре бигрәк тә ислам илләре белән тыгыз.

Республиканың «Вакуммаш», компессор заводы, «Данафлекс», Татхимфармпрепаратлары», «Палп-индекс» оешмалары яңа уңышларга ирешә тора. Машиналар, техник җиһазлар, дарулар, кәгазь, резина, пластмасса эшләнмәләре арта тора. Авиация заводында ТУ-214 самолетларын җыю башланды, вертолет заводы «Ансат»ка кирәк детальләрне үзе булдыра башлады. Республикада азык-төлек җитештерү сизелерлек арткан.

Донбасс – татарлар өчен ерак араны якын иткән җир. Анда шахталар барлыкка килеп, күмер чыгара башлаганнан бирле, меңләгән татар шахтерлык һөнәрен ныклап үзләштерә тордылар. Бүген анда 40 меңнән артык милләттәшебез яши. Аларның үз оешмалары бар. Татар конгрессы белән һәрвакыт элемтәдә торалар.

Татар язмышы беркайчан да җиңел булмады. Ләкин утны-суны кичеп, тарихта чарланган халкыбыз авырлыкларны, кайгы-хәсрәтләрне лаеклы рәвештә җиңә килеп, үзенең мәңгелегенә юл ача килде. Шикләнмим: татарның мәңгелеге өмет кенә булып калмас, чынбарлыкка әверелер.

Индус ТАҺИРОВ

МАМАДЫШ ТӨЗҮЧЕСЕ РОБЕРТ СӘЛАХЕТДИНОВ:

«Боздан атнага 100ләп фигура ясыйм»

Мамадыш районында яшәүче төзүче-рәссам Роберт Сәлахетдинов төсле буяулар белән генә түгел, кар һәм боздан да әллә нинди могҗизалар тудыра. Аның сыннары район оешмалары, кешеләрнең капка төпләрен бизи. Төп нигезе дә әкияткә тиңләрлек аның.

– Туган йортымның капкасы янында сыннарны дүртенче ел ясыйм инде. Үземнең йортым да аннан ерак түгел. Чыршы, көймәдәге куяннар, узып баручы ел символы юлбарыска утырган куян, агач төбендәге калач, чебен гөмбәсе… Болар барысы да – якыннарыма Яңа ел бүләге. Вакыт булса, тагын яңа геройларны өстәрмен, – ди 43 яшьлек сынчы.

Оешмалар, мәктәпләр дә бәйрәм кәефе өстәргә чакыра аны. Гадәттә, бер атна эчендә 100ләп фигурага җан өрә. Нинди генә җәнлекләр иҗат итмәгән?! Иртән сәгать 5тә торып, төнге 12гә кадәр дә эшләгән чаклары була икән. Заказлар күп, тик өлгереп кенә бетеп булмый, ди. Аның әйтүенчә, атнага бер шедевр да, шул ук вакытта 100ләп сыйфатлы персонаж да ясап була. Шулай ук районодашлары арасында үз капка төпләрен бизәтүчеләр дә бар. Матурлыкны кем яратмый!

Роберт – һөнәре буенча төзүче. Республиканың төрле район һәм шәһәрләре буйлап йортлар төзеп кенә калмый, аларны бизәргә дә булыша. Шифаханә, ресторанмы, мәктәп, балалар бакчасымы – кая барса да, кулына тизрәк пумала ала. Краснодар, Санкт-Петербургка сәяхәтләрендә күргәннәрен дә кәгазьгә төшергән. Ясаган картина, рәсемнәре 10 меңнән арткан инде.

Беренче тапкыр сыннарны 1999 елда армиядән кайткач Түбән Камада ясаган ул. Шунда рәссам-бизәүче булып эшкә урнашкан. Шул ук вакытта Чаллы дәүләт педагогика институтында шушы юнәлештә белем алган. Биш ел читтән торып Казан дәүләт архитектура-төзелеш институтында укыган, тик әле диплом алмаган.

Матурлык яратучы егеткә тормышта төрлесен күрергә туры килгән. Кавказда «кайнар нокта»ларда хезмәт иткән. Берничә тапкыр юл фаҗигасенә очраган. 2013 елда өч тапкыр операция кичергән. Сынауларга карамастан, ул дөньяны төрле матур төсләрдә күрергә тырыша, аннан яктылык эзләүдән туктамый.

– Аллаһы Тәгалә гомеремне саклады. Кешеләргә яхшылык эшлисем бар, димәк. Быел районадагы бер авылда Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл төзедем. Гел акча дип кенә торып булмый. Кайчак бушлай да эшлим. Мәктәптә балаларга рәсемнәр ясыйм. 45 яшемә, иҗатыма багышлап, күргәзмә оештырасым килә, – диде Роберт Сәлахетдинов.

Сәрия МИФТАХОВА

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Тест

МОГҖИЗАЛЫ БӘЙРӘМ

Яңа ел – иң якты, кызыклы, көтеп алынган бәйрәмнәрнең берсе. Урамнарда һәм өйләрдә чыршылар бизәп куелган. Барысы да бүләкләр, теләкләр, могҗиза көтә. Әлеге тылсымлы бәйрәм турында белемнәрегезне тикшереп карагыз әле.

1. Россиядә Яңа ел чыршысы кем указы белән барлыкка килә?
а) Александр I;
б) Екатерина II;
в) Петр I;
г) Александр II.

2. ... – Халыкара Кар бабай көне.
а) 1 гыйнвар;
б) 18 гыйнвар;
в) 14 март;
г) 31 декабрь.

3. Кар кызы – Кыш бабайның ...
а) кызы;
б) әнисе;
в) оныгы;
г) әбисе.

4. Кар бабайның туган елы?
а) 1493;
б) 2000;
в) 1076;
г) 1990.

5. Чыршының иң очына куела торган йолдыз ул – ...
а) таң йолдызы;
б) Вифлеем йолдызы;
в) Коммунистлар партиясенең символы;
г) күк йолдызы.

6. Дөньяда иң биек Кар бабайны (38,04 метр) кайсы илдә ясаганнар?
а) АКШ;
б) Австралия;
в) Чехия;
г) Австрия.

Җаваплар: 1) в; 2) б; 3) в; 4) а; 5) б; 6) г.

ЕЛ ВОЛОНТЕРЫ САИМӘ ШАҺИӘХМӘТОВА:

«ҮЗ ТАРИХЫН БЕЛМӘГӘННЕҢ КИЛӘЧӘГЕ ЮК»

«Мәрхәмәтле Татарстан» бәйгесенең гражданлык-патриотик эш юнәлеше җиңүчесе, яшь волонтер Саимә ШАҺИӘХМӘТОВА әнә шулай ди. Кешеләргә булышудан тәм табып яшәүче кыз авылында һәм районында төрле патриотик акцияләр оештыруда катнаша, өлкәннәрнең һәм ветераннарның хәлләрен белешә, йорт, бакча эшләрендә булыша.

:: Саимә, волонтерлык хәрәкәтенә ничек кушылдың?
– Волонтер булу теләге кечкенәдән бар иде инде. Мәктәптә укыганда «Форпост» мәктәп берләшмәсе командиры булдым. Хәзер институтта патриотик эшчәнлек алып барам. Туган авылымны һәм районымны да калдырмыйм, яңа проектларны тормышка ашырам. Быел мәктәптә чаралар үткәрүне һәм ветераннарыбызга йөрүне дәвам иттердек.

:: Патриотик волонтерларниләр белән шөгыльләнә?
– Без Бөек Ватан сугышы ветераннарына, районның тыл хезмәтчәннәренә, ялгыз пенсионерларына ярдәм итәбез. Шулай ук төрле патриотик акцияләр, флешмоблар, күңелле физик күнегүләр үткәрәбез. Шул рәвешле һәркемне сәламәт яшәү рәвеше алып барырга чакырабыз.

:: Син быел гражданлык-патриотик эш өлкәсендә Ел волонтёры булдың. «Мәрхәмәтле Татарстан» бәйгесендә җиңү күптәнге хыялың идеме?
– Мин күп кенә конкурсларда үз көчемне сынап карыйм, үзем өчен белем һәм тәҗрибә тупларга тырышам. «Мәрхәмәтле Татарстан» бәйгесендә катнашуга күптәннән әзерләндем. Былтыр финалист булдым, 2022 елда җиңүгә ирешү максатын куйдым. Һәм шулай булды да.

:: Бүгенге буын патриотик түгел дигән фикер белән килешәсеңме?
– Бу фикер белән килешмим. Минем тирәмдә туган ягын кадерле һәм аның тарихын өйрәнә торган патриотик яшьләр бар. Бу бик мөһим, чөнки үз тарихыңны белмәсәң, киләчәгең юк. Яшьләргә иҗтимагый тормышта актив катнашырга, кешеләргә булышырга кирәк. Кемгә дә булса ярдәм итеп, син иң элек үзеңә булышасың.

КУНАГЫБЫЗ ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ
- Саимәгә – 17 яшь.
- Питрәч районының «Форпост» балалар иҗтимагый оешмасы рәисе, җирле яшьләр хокук саклау хәрәкәте лидеры.
- КФУның филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының беренче курсында белем ала.
- Киләчәктә башлангыч сыйныф һәм инглиз теле укытучысы булачак.

:: Студент тормышын һәм актив волонтерлык эшчәнлеген бергә алып бару кыен түгелме соң?
– Иң мөһиме – теләк һәм үз максатыңа ирешергә омтылу. Шул очракта барысына да вакыт җитә.

:: Кешеләргә ярдәм итү синең өчен нәрсә ул? Булышканда нинди хисләр кичерәсең?
– Хәзер минем өчен волонтерлык – яшәү рәвеше. Кемгә дә булса булыша алуымнан тәм табып яшим, бу эшне чын күңелемнән яратам. Кешеләргә ярдәмгә килгәндә, алар ачык йөз белән каршы ала, күзләрендә нур балкый. Өлкәннәрнең рәхмәт сүзләрен ишетү рәхәт. Үзләренә булган аз гына игътибардан да күңеле була, яшәү дәрте арта бит аларның.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Күңелле яңалык

Сабыйларга – бүләк

Сезгә күңелле яңалыгыбыз бар бит әле. Тиздән Туфан Миңнуллинның легендар «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәре янә тамашачы хозурына кайтачак! Тик бу юлы спектакль рәвешендә түгел, ә мультфильм формасында. Әсәр буенча «Татармультфильм» студиясе эшләгән тулы метражлы анимацион фильм тиздән прокатка чыгачак.

– «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәре – татар мәдәнияте легендасы. Туфан Миңнуллин, Шәүкәт Биктимеров, Марсель Сәлимҗанов – татар театры, мәдәнияте, гомумән, татар халкы тарихына алтын хәрефләр белән язылган исемнәр. Без мираска бик сак карадык: төп сюжетлы линияләргә артык кагылмадык, кызыклы итеп эшләргә тырыштык. Бу безнең килеп чыкты дип уйлыйм, – диде фильмны тәкъдим итүгә багышланган матбугат очрашуында «Татармультфильм» берләшмәсе җитәкчесе, проектның сәнгать җитәкчесе Марат Ганиев.

Бөек драматургның әсәрен инде күптән экранлаштырырга хыялландык, ди анимацион фильм режиссеры Сергей Киатров:

– «Татармультфильм» әле оеша гына башлаганда, ул безгә гел ярдәм итеп торды. Туфан абый үзе «Әйт әле, күбәләк»не тәкъдим итте, ләкин ул бик театраль, анда диалоглар да күп һәм без шулай «Әлдермештән Әлмәндәр»гә тотынырга булдык.

Анимацион фильм эшләүгә 20дән артык иллюстратор, якынча 30 аниматор җәлеп ителгән. 68 минутлык мультфильм 1126 сәхнәдән тора, барлыгы 90 персонаж булдырылган.

Анимацион фильмны рус һәм башка телләргә дә тәрҗемә итәргә планлаштыралар икән.

– Шул ук музыкага рус телендә җырлар язабыз. Анда татар мәдәнияте һәм җырларының мәгънәсе дә сакланачак һәм аларны шул ук актерлар тавышландырачак. Кыскасы, рус телендә дә татар колориты калачак, – дип сөйләде фильм режиссеры.

Сценарий төркеме җитәкчесе Алсу Низамиева әйтүенчә, спектакльдә күбрәк диалогларга өстенлек бирелсә, мультфильмда персонажлар вакыйга һәм локацияләр аша ачыла.

– Спектакль – башка, анимацион фильм – сәнгатьнең бөтенләй башка төре. Әлмәндәр – татар халкының символы. Аңа безнең халыкка хас булган традицияләр, зирәклек, кайсыдыр дәрәҗәдә хәйләкәрлек тә хас. Бу персонажны тирәнрәк ача алдык дип уйлыйм, – диде ул.

Төп геройларны Галиәсгар Камал театры артистлары: Әлмәндәр ролен – Эмиль Талипов, Искәндәрне – Илнур Закиров, Әҗәлне Россия һәм Татарстанның халык артисты Равил Шәрәфиев тавышландырган.

– Тәкъдим килгәч, дөресен әйтергә кирәк, башта бик шикләндем. Бер үк елгага икенче мәртәбә керү булмый микән дип уйлап куйдым. Тик бу кабатлау түгел, бөтенләй башка булып чыкты, – ди Равил Шәрәфиев. – Спектакльдә Әҗәл роле бирелгәч, мин моңа бик теләп алынмадым. Әлмәндәрне уйныйсы килә иде. «Әҗәлнең аның нәрсәсен уйныйсың инде?» – дип уйлый идем. Тик образга кергәч, капма-каршы булган Әлмәндәрнең оптимизм, тормыш яратуы аңа да күчә башлады кебек. Мин Әҗәлне дә кеше итә торган фикерләренә, рухына чумдым. Дөньяда үлем генә түгел, яшәү, кешенең рухы бар. Бу мультфильмда менә шул рухның көчлелеге күренә. Монда ул фикер спектакльгә караганда да күбрәк һәм көчлерәк әйтелә сыман.



Безгә язалар

Еламаска өйрәндем

Мин әниемне беренче сыйныфта укыган вакытта ук югалтсам да, аның турында бик күп нәрсәләрне хәтерлим. Әнием урынына калган әбием, Чулпан һәм Энҗе апаларымнан да әнием турында кат-кат сораштырам. Аеруча Энҗе апамнан: «Әнием турында сөйлә әле», – дип сорыйм, чөнки әнием белән соңгы елларда хастаханә юлларын ул таптады. Менә сезгә дә апам сөйләгәннәрне җиткерергә булдым. Биредә язылганнарны укып, берничә генә кеше булса да гыйбрәт алып, вакытында хастаханәгә барып, гомерен саклап калса, табиблар да авыруларга карата мәрхәмәтлерәк булса, мин бик шат булыр идем…

«…Әниеңнең тешләре кителеп төшәргә тотынды. Мичтән акбур кубамыни, барысы да ком кебек уалып саргаеп бетте. «Табибка күренергә кирәк, дөрес хәл түгел бу», – дигәнемә дә каршы килде ул. Шулай бер айга якын вакыт узды. Без хастаханәгә эләктек. Табиблар антибиотик билгеләде. Бераздан теш табибын алып килделәр. Ул Казан табибларына күренергә дигән фикердә торды. Әниең курыккандыр инде, өченче көнне аны анализларга йөрткәндә медицина язуын алып карасам, Казан хастаханәсенә барудан баш тартам дип кул куйган. Алга китеш юк. Теш табибы да Казан ди, мин дә анда бару яклы.

…Кич белән әниең шалтыратты. «Мине килеп ал әле, хастаханәдән чыгардылар», – ди. Ышанасыңмы-юкмы? Тышта караңгы. Аны кичен, нинди авыр хәлдә юллама тоттырып, урамга чыгарып җибәргәннәр! Авылга кадәр унбиш чакрымны ул ничек кайтып җитәргә тиеш булгандыр, әмма безгә, авыруны алып китегез, дип шалтыратучы булмады. «Мин Казанга нәрсә белән барыйм?» – дип сорагач, әниеңә хирург: «Әнә автовокзал янында таксилар күп, шуның белән бар», – дип җавап биргән.

Икенче көнне Казанга чыгып киттек. Хастаханәгә барып җиткәнче, берничә мәртәбә аңын җуеп егылды. Әниеңә алты сәгать ярым операция ясаганнар. Бер ай була дигәндә аны торакаль хирургия бүлегенә күчерделәр. Ул ятачак палатага алданрак килдем һәм аны көтеп утырдым. Ул, мине күреп, кочакларга үрелде. Бар да артта калган кебек иде. Тик ун көннән соң кан тамыры шартлап, кан китте, ашказанына куелган шланг та уңышлы булмады, яңадан операцияләр ясадылар. Операция арты операция булып кына торды. Унбер тапкыр пычак астына ятарга туры килде аңа. Сөйләшә алмаганлыктан, дәфтәргә язып кына аңлаша идек. «Өйгә кайтам бит, өйгә!» – дип язганын бүген дә оныта алмыйм.

Авылга кайткач та, аны эченә куелган шланг аша тукландырдык. Янәдән Казанга килгәч, әниеңнең хәле кисәк авыраеп китте, кабат муены шеште. Табиблар киңәшергә җыелдылар һәм, калган теш төпләре ялкынсынып ятадыр дип уйлап, бер юлы бөтен тешләрен дә алырга булдылар. УЗИ үткәч кенә, әниеңнең, суык тидереп, муенына, үпкәсенә су җыелганы билгеле булды.

Яңадан авылга кайттык. Килеп күренеп йөрергә куштылар. Бик еш Казан юлын таптадык. Ярты елдан әниеңнең тавышына зыян килгәнлеге, тавыш ярыларының параличланганы беленде. Ул һаман да әле трубка аша сулый, шланг аша сыек ризык кына каба, язышып кына аралаша иде. Озакламый зур сөенеч булды. Табиблар аңа элеккечә ашап карарга рөхсәт бирделәр. Менә шундый сынаулар аша үтәргә туры килде безгә, сеңлем. Ә аннан соңгы тормышны син үзең дә хәтерлисең, беләсең инде», – дип тәмамлады апам.

Әйе, мин барысын да хәтерлим. Тик миңа әни кочагында үсәргә насыйп булмады. Ул озак тормады, мине ятим калдырып, мәңгелеккә китеп барды. Әмма мин әниемнең назлы кулларын, аның яратуын әле дә тоям. Ятимлек ачысын сиздермәгән өчен әбиләремә, апаларыма мең рәхмәтлемен! Һәр бала әниле булсын иде. Еллар узса да, җитмисең бит, әни! Менә бүген буй җиткән кызың белән горурланыр идең дә бит! Тиздән мәктәпне тәмамлыйм. Тырышып укып йөрим. Синең күкләрдән күзәтүеңне беләм мин! Әбиләрем дә сөеп кенә яшәтә. Дусларым күп. Мин инде күптән еламаска да өйрәндем. Син генә риза бул!

Эльвина ИВАНОВА,
Балтач районы Түнтәр урта мәктәбенең
11 нче сыйныф укучысы

Нәни рәссам почмагы

Мин кечкенәдән рәсем ясарга яратам. Карандаш, фломастер, төрле буяулар белән ясау ошый. Шуңа күрә рәсем түгәрәгенә дә йөрим. Анда без төрле пейзажлар, натюрмортлар ясыйбыз. Гомумән, буш вакытымда ирекле темага рәсемнәр төшерәм. Бер көнне төнге урмандагы төлкене күзаллап ясадым. Ә сез буш вакытларыгызны ничек уздырасыз?

Иделия Бәдертдинова. Актаныш, 7 яшь

Сәхифәне Ләйсән САФИНА әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6692 данә
Гомуми тираж – 15344 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 393

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+